
# Татарстан - туган ягым.




100 лет
образования
ТАССР

# ТАССР

## 1920 - 2020



Туган җир – ата-бабалардан калган мирас,
шуңа да ул безгә кадерле.



# ИДЕЛ – ЙОРТ











И Идел-йорт, Идел-йорт,
Идел буе имин йорт,
Ата-бабам тоткан йорт,
Ашлык бел□н тулган йорт;
Идел-□ аек арасы
Елкы бел□н тулган йорт;
Казан-Болгар арасы
Кала бел□н тулган йорт.
Котлы булсын туган йорт...


НМРТ



# ТАССР ничек төзелгән?

**1920 елның 26 гыйнварында** Мәскәүдә большевиклар Россия Федерациясе коммунистлар партиясенең үзәк комитетының сәяси бюросында Татарстан Совет Социалистик Республикасын булдыру турында принципиаль карар кабул ителә. Шул ук вакытта булачак республиканың чикләрен билгеләү өчен **Сәхибгәрәй Сәетгалиев** җитәкчелегендә административ комиссия булдырыла.

**1920 елның 22 мартында** РСФСР халык комиссарлары советы рәисе Владимир Ленин Татарстан Республикасы оешу турында фикер алышу өчен Кремльдә инкыйлабчы, Татарстан Республикасын төзүчеләрнең берсе, 1920-1921 елларда Татарстан АССР Үзәк башкарма комитеты рәисе Борһан Мансуровны һәм Татарстан Республикасын булдырган, аның беренче хөкүмәт җитәкчесе булган Сәхибгәрәй Сәетгалиевны чакыра.

1920 елның феврале азагында Татарстан АССР турында нигезләмә бастырыла. Нигезләмәдә республиканың булачак териттoриясе турында да әйтелә. Татар халкы өстенлек иткән түбәндәге биш губернаның районнарын кушып кую планлаштырыла: Казан, Уфа, Самар, Сембер һәм Вәтке. Нигезләмәдә ТССРга кертелергә тиешле өязләр һәм вулыслар гына түгел, кече шәһәр һәм авыллар да санала. Шулай итеп сәяси картада **Автономияле Татарстан Социалистик Совет Республикасы** барлыкка килә.



pastvu.com/515665

# Учредительный съезд ТАССР



**Бөтенроссия Үзәк Башкарма Комитеты һәм РСФСР халык комиссарлары советы 1920 елның 27 маендагы декреты белән Автономияле Татарстан Социалистик Совет Республикасы (АТССР) барлыкка килә.**


Татарская АССР
РСФСР
Татарская АССР
ПРОЛЕТАРИИ ВСЕХ СТРАН СОЕДИНЯЙТЕСЬ!
БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИАСЫ БЕРЛӘШЕГЕЗ!
Татарская АССР


***27 мая 1920 г. Казань стала столицей Татарской АССР***






ПЕРВЫЙ СОСТАВ 1-ой ПАРТ. ШКОЛЫ 6-го РАЙОНА ЗАПАС. АРМ. РЕС. В КАЗАНИ. 1920 ГОД.

# (!) НЭП
# (новая экономическая политика)



- экономическая политика, проводившаяся в Советской России. Была принята *15 марта 1921 года X съездом РКП(б)*, сменив политику «военного коммунизма».

# 1921-1922 еллар ачлыгы

**1921-1922 еллар ачлыгы**, Татарстанда хәрби коммунизм нәтиҗәсендә 1921 елның көзендә башлана. Ачлык афәтенә 2 миллионнан артыграк кеше дучар була.
ТАССР хөкүмәте 1921 елның ахырында ачларга ярдәм оештыру комиссиясе төзи. Авыл һәм шәһәрләрдә ачка интегүчеләрне дәүләт һәм җәмәгатьчелек ярдәмендә ашату пунктлары оештырыла. Ачлык нәтиҗәсендә ТАССР халкы 400-600 мең кешегә кими, 86 мең крәстиян хуҗалыгы (16,2%) юкка чыга.


1921-1922 еллардагы
АЧЛЫК ВАКЫТЫНДА
5 МИЛЛИОН КЕШЕ
ҺӘЛАК БУЛА
Тарих фәннәре
кандидаты
Тәэминә
БИКТИМЕРОВА
1921 елгы
ачлык турында
ТИ

# НЭП (1921 – 1929 гг.)









Материалы зала рассказывают о периоде 1921-1929 гг., получившем название «новой экономической политики».

# Татар әдипләре-сәяси репрессия корбаннары

**Сталинизм – илебез халыкларының уртак фаҗигасе. Сталин репрессияләре бер генә төбәкне дә, бер генә халыкны, бер генә милләтне дә читләтеп узмаган. Татар халкынның да бик күп асыл затларын юк иткән. Никадәр җәмәгать-дәүләт эшлеклеләре, хуҗалык җитәкчеләре, мәдәният әһелләре, галим, язучы, мөгаллим, рәссамнар һәм башкалар башын салган анда…**

**Репрессия, иң беренче чиратта, халыкның иҗатчыларына, иҗтимагый,мәдәни хәрәкәттә әһәмиятле роль уйнаган алдынгы карашлы катламына юнәлтелә.**

# Сталинизм – илебез халыкларының уртак фаҗигасе



# 1918, 1924, 1930, 1935, 1936 нчы еллар

Татарның тарихы фаҗигаләрдән генә тора, аның күренекле шәхесләрен яки үтергәннәр, яки алар көрәштә һәлак булганнар, яки алар зинданнарда череттелгәннәр. М.Солтангалиев, Һ.Атласи, Г. Гобәйдуллин, Г.Нигъмәти, Җ.Вәлиди, М.Галәү, К. Тинчурин, Г.Гали, Г.Толымбай, Г.Ибраһимов, Ш. Усманов, М.Мутин, Ф.Бурнаш, Л.Гыйльми, С. Сүнчәләйләр Совет зинданнарында җәзалап үтерелде. Г.Хәсәнәт, М.Шабай, Г.Исмәгыйлев, К.Җаманаклы, К. Нәҗми, Н.Исәнбәт, Б.Урманче, М.Әмир, Х.Туфан, А. Гыйләҗев, А.Тимергалин, С.Рәфыйков, Г.Ильясов, Г. Талин Совет зинданнарында җәзаланды.



Галим□ ан Ибра□ имов



Салих С□ йд□ шев



Бакый Урманче



Александр Бутлеров



Максим Горький



Гаяз Исхакый

# *Сөргеннәргә сөрелгән Туфан*



“Танып алдым Туфан сагышларын
Урал аша аккан болыттан”. (Н. Әхмәдиев)
(1900 - 1981)

# Хәсән Туфанның тоткынлыкта булуы

1940 - 56 елларда Хәсән ага тоткынлыкта була. Газап, кайгы- хәсрәт, үлем белән күзгә - күз очрашу чоры бу. Язмыш аны сындырып сыный... Ләкин шагыйрь иманына, халкына, иленә тугры кала.

1937 нче елда "Ант" поэмасы өчен Хәсән аганы Язучылар Союзыннан чыгаралар. Әсәрләре басылмый, китаплары тоткарлана. Көн саен, төн саен кулга алуларын көтеп яши ул.

Х. Туфан колониядә үз срогын тулысынча тутыра. Коточкыч арый, йончый. Физик яктан да, рухи яктан да Хәсән абый түземсезлек белән ирекка чыгу көннәрен көтә. Әмма бер сүз дә аңлатып тормыйча аны, Себергә мәңгелек сөргенгә җибәрәләр.

Х. Туфанның тоткынлык дәвере 16 елга сузыла. Сталин үлеп, аның сәясәтендәге җитди хаталары ачылганнан соң гына, шагыйрьгә ирекка чыгарга мөмкинлек туа. 1956 нчы елның җәендә ул Казанга кайтып төшә.

Ул өенә кайтканда аның улы да, хатыны да үлгән була инде, тик кызы гына һәм язучы дуслары гына каршы ала.

# Кайсыгызның кулы җылы?



Дөнья мине
Үзгәртте:
Еламаска өйрәтте.
Көлмәк җиңен ертасымы? —
Бәйлисе бар
Йөрәкне.
Сугышлардан замана
Туктап торган арада,
Яраларны ямаштырып
Ята идем
Далада:
— Кайт!.. — дип хатлар килделәр...
Юллар... озын иделәр...
Кайттым.
— Бусы алкалары,
Бусы — кабере... — диделәр.
Әгәр тагын килсәләр,
— Сау! — дип хәбәр бирсәләр,
Вулканнарга керер идем,
Шундадыр ул... дисәләр.
Бирде дөнья кирәкне,
Еламаска өйрәтте...
Кайсыгызның кулы җылы?
— Бәйлисе бар йөрәкне...

Хәсән Туфанның музей-йорты Аксубай районы Иске Карәмәт авылында урнашкан.






**Бу музей Хәсән Туфанның үткән тормышы турында сөйли.Анда бик күп төрле иҗаты турындагы язмалар сакланган.**
**Хәсән аганың үз әйберләреннән: күлмәге (хәсән Туфан аны үзе теккән), хатыны Луиза ханымның документлары,Хәзерге көннәргә кадәр дә эшләүче механик-сәгате, 30 нчы елларда басылган беренче китабы, китап шкафы,көзге,Чемодан,Самовар, чәйнек һәм башка, санап бетергесез күп әйберләр.**

# ТАТАРЛАРНЫҢ МИЛЛИ КИЕМНӘРЕ



# ТӨП ДИН – ИСЛАМ ҺӘМ ХРИСТИАН ДИНЕ





# ТАТАРСТАННЫҢ ДАНЛЫКЛЫ КЕШЕЛӘРЕ




Ханбикә Сөембикә



Габдельҗаббар Кандалый



Кол Гали



һади Такташ



Каюм Насыйри



Муса Җәлил



Фатих Әмирхан



Габдулла Тукай



Абдулла Алиш

# Татарстан – туган ягым.











- Олуг хезмәтләре белән
- данлылар





**Бакый Урманче (1987-1990) –татар профессиональ сынлы сәнгатенә нигез салучы,рәссам, график, скульптор һәм архитектор**





- М. Сәлимҗанов иҗаты – татар театры тарихында үзе бер зур чор



Президент рәссам И. Зарипов белән






**- Егерме беренче гасырга без атаклы җырчы Илһам Шакиров моңы белән керербез.**



Әлфия Авзалова, Илһам Шакиров.
Концерт финалы. 2006 ел




**Әлфия Авзалова Минтимер Шәрип улы Шәймиев белән. 2003 ел**

# Алар мәңге безнең күңелләрдә…





“... Җырларда җырланган туган туфрак.
Ата-бабамның каны тамган,
ата-анамның тире түгелгән,
әнкәм-әбиемнең
күз яше белән сугарылган изге туфрак”.

Әхмәт Әһлиуллин

# НОВЕЙШАЯ ИСТОРИЯ ТАТАРСТАНА



Ввиду распада СССР и прекращения его существования вследствие Беловежских соглашений, 26 декабря 1991 года Верховный Совет Татарии принимает Декларацию о вхождении республики в Содружество Независимых Государств на правах учредителя.

7 февраля 1992 года Татарская ССР – Республика Татарстан переименована в Республику Татарстан.

Декларация о суверенитете

# В нашей республике Конституция принималась 4 раза





13 марта 1926 года

25 июня 1937 года

**31 мая 1978 года**

**6 ноября 1992**





Мәйданы — 68 мең кв. км
Халкы — 4 млн. га якын
Административ районнар — 43
Табигый байлыклары — нефть, газ, торф, известьташ
Елгалары — Идел, Кама, Вятка, Мишә, Зөя, Ык, Агыйдел
Климаты — уртача континенталь

Площадь республики — 68 тыс. кв. км
Население — около 4 млн человек
Административные районы — 43
Природные богатства — нефть, газ, торф, известняк
Крупные реки — Волга, Кама, Белая, Вятка
Климат — умеренно-континентальный

**1990 елның 30 августында** ТАССР Югары Советы “Татарстанның дәүләт суверенитеты турында” декларациясен кабул итә һәм республика атамасын “Татарстан Совет Социалистик Республикасы – **Татарстан Республикасы**”на үзгәртә.

*17* **мая** *1920* **г.**
**был подписан Декрет об образовании**


*30* **августа** *1990* **г.**
**была принята Декларация о государственном суверенитете республики**






**1992 елның 7 февраленнән республика – Татарстан Республикасы атамасын йөртә.**
1992 елның 21 апрелендә РСФСР халык депутатлары җыены бу атаманы раслый һәм РСФСР Төп канунына тиешле үзгәрешләрне кертә.

Татарстанның беренче президенты- Минтимер Шәрип улы Шәймиев.



# Яратабыз сине, Татарстан!



- Татарстан Идел буенда урнашкан һәм аның мәйданы 68000 кв. км дип исәпләнә.  Халык саны – 3 миллион 700 мең кеше. Татарстанда 100 артык  төрле милләт халыгы тора.




Татарстанда
төрле милләт
вәкилләре яши
Богатые Сабы
Высокая гора
Рыбная Слобода
Нижнекамск
Лаишево
Апастово
Алексеевск
Новошешминск
Тетюши

Татарстан Республикасы составына 43 район, 19 шәһәр, 21 шәһәр типындагы авыл һәм 3000 якын авыллар керә. И   зур шәһәрләргә сез белгәнчә - Казан, Чаллы, Түбән Кама, Бөгелмә, Чистай, Алабуга, Яшел Үзән керә.



# ТАТАРСТАН Республикасыны символлары






# Татарстан гербы.

Барс халыкны көчен белдерә.

Барсны ян-ягына калкан – именлек билгесе, һәм кашкарый чәчәге – озын гомер билгесе сурәтләнгән.



**Татарстанны Дәүләт флагы өч өлештән тора:**

**өске өлеше – яшел,** туган иребезне һәм табигатьне матурлыгы төсе;

**аскы өлеше – кызыл,** кояш һәм ут төсе;

**ә уртада ак** кына тасма сузылган – намус, тынычлык-иминлек билгесе.



# Татарстанны

**Дәүләт гимны**

1993 нче елда
кабул ителде.

Ул куренекле
композитор-

**Рөстәм Яхин**
**музыкасына**
**язылган.**



# Татарстан Республикасының Дәүләт гимны

**Мәңге яшә, газиз Ватаныбыз,**
**Халкым тели изге теләкләр!**
**Гомерлеккә якын туган булып**
**Яши бездә төрле милләтләр.**

**Күп гасырлар кичкән чал тарихлы**
**Данлы илем үзең бер дастан!**
**Синдә генә безнең язмышыбыз,**
**Республикам минем Татарстан!**


ТАССР
Празднование 100-летия
Татарской АССР
Татарстан АССР төзелүнең
100 еллыгын бәйрәм итү
1920-2020

**ТАССР самолетлар һәм вертолетлар, электрон исәпләү машиналары, компрессорлар, нефть аппаратурасы, сәгатьләр һәм медицина инструментларын шул елларда тышкы базарда конкурентлыкка сәләтле дәрәҗәдә җитештерде.**








Түбән Кама нефть химиясен бердәм технологик циклга берләштерүче "Оргсинтез" берләшмәсенең беренче җайланмалары җибәрелде. Полиэтилен һәм полиизопрен каучук житештерү линияләре сафка басты. 1973 елда Түбән Кама шин заводы беренче продукциясен чыгарды



# КамАЗ
# төзелү Татарстанны иң алдынгы автомобиль төзелеше төбәге буларак танытты






**1950 елда Советлар Союзының иң эре нефть чыгаручы берләшмәләренең берсе "Татнефть" төзелде, шул еллар ахырына Татарстан нефть чыгару күләме буенча илдә беренче урынга чыкты.**






Чистопольский
часовой завод




Татарстан аша дурт зур елга ага: Идел, Чулман, Агыйдел, Нократ, шулай ук кечкенә елгалар һәм кулләр.







Нинди матур, нинди гузәл безнең
Казан дигән данлы башкала.
Кайсы илдән кем генә килсә дә,
Бу каланы күреп таң кала.

*Р. Нургалиева*


1000 лет
КАЗАНИ
КАЗАНГА
1000 ел
КАЗАНСКИЙ КРЕМЛЬ. Благовещенский собор
КАЗАН КРЕМЛЕ. Благовещение соборы

# Сөембикә манарасы



**Казан Кремле эчендә урнашкан Сөембикә манарасы танылган архитектура символы.**



# Г.Камал исемендәге татар дәүләт театры бинасы








# Татарстан шәһәрләре



Казан



Яр Чаллы



Әлмәт



Алабуга



Түбән Кама

# Алабуга






**Соңгы елларда югары технологияле комплексны төзү буенча иң зур проект -"ТАНЕКО" проекты булды. Беренче этапта – ел саен анда 7 млн.тонна югары күкертле нефть киң күләмдәге товар продукциясе итеп эшкәртелә.**




НПЗ Татнефть ТАНЕКО Түбән Кама

# Татарстан шәһәрләре



Минзәлә




Зәй



Баулы



Чистай




Бөгелмә

Шәһәрләрдә парклар, музейлар, мәчетләр, чиркәүләр бар. Татарстанда куе урманнар, киң кырлар, күлләр бар.





Президент Республики Татарстан Минниханов Рустам Нургалиевич


Татарстанны Яратам
30 Августа
День Республики
Татарстан
#ЛюблюТатарстан


ТАТАРСТАН
Татарстан — минем Республикам
Мәңге яшә, газиз Ватаныбыз,
Халкым теле изге теләкләр!
Гомерлеккә якын туган булып
Яши бездә төрле милләтләр.

Күп гасырлар кичкән чал тарихлы
Данлы илем, үзең бер дастан!
Синдә генә безнең язмышыбыз,
Республикам минем, Татарстан!

# Казанда тарихи урыннар









Кол Шәриф мәчете Казанның төп дини һәм
истәлекле урыны булып санала.һәм 2005 елда
Казаннын меңеллыгына аны яңадан
торгызырга булдылар. Кол Шәриф мәчете,
шулай ук,Казан Кремле эчендә урнашкан.
Nikita
Pshenichnikov

«Без – табигать хуҗалары, табигатьне саклау – ул туган илеңне саклау»

# Музыка

## *Бергәләп җырлап алыйк!*

**И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле!**
**Дөньяда күп нәрсә белдем син туган тел аркылы.**

**Иң элек бу тел белән әнкәм бишектә көйләгән,**
**Аннары төннәр буе әбкәм хикәят сөйләгән.**

**И туган тел! Һәрвакытта ярдәмең белән синең,**
**Кечкенәдән аңлашылган шатлыгым, кайгым минем.**

Туган телемдә сөйләшеп
Яшим мин туган илдә.
“Туган ил” дигән сүзне дә
Әйтәм мин туган телдә
Иң изге хсләремне мин
Туган телдә аңлатам
Шуңа күрә туган телне
Хөрмәтлим мин,яратам!

***Идел ярларына нурлар сибеп,***
***Матур булып ата бездә таң.***
***Таң шикелле якты туган илем,***
***Бәхет биргән җирем – Татарстан!***

***(Г. Зәйнәшева)***

# Туган авыл, туган нигез



*Яшәр өчен бетмәс көч*
*алырга*
*Олысына һәм дә кечегә,-*
*Мәхәббәтле, ямьле,*
*мәрхәмәтле*
*Туган ягы кирәк кешегә.*

*Зур уңышлар яулап,*
*заманалар*
*Матур бәя бирсә эшенә, -*
*Шатлыкларын ишеттерер*
*өчен,*
*Туган ягы кирәк кешегә.*

# *Кыязлым- гомер язым.*



Болгар зиннәтләрен саклап,
Дини йолаларны барлап,
Изге кыйбласына карап,
Яши авылым кыю атлап.

Туган җирем Кыязлым,
Синдәдер тәүге язым.
Сөлчә  суы ярларында
Тузганаклар алтынсыман

Халкым тыйнак, алтын йөзле
Эштә кыю ялкынсыман.
Туган авылым Кыязлым,
Кыязлым гомер язым.

Мең гасырлык сагыш,ярсу
Дулкынлана  җырларыңда
Гөлләр, җилләр мәгърүр юлдаш
Газиз гомер юлларымда.

*И! Кыязлым, Кыязлым!*
*Хикмәтле күңел язым.*

(Гөлчәчәк Әдһәмова  )

Чал тарихлы туган илем,
Кырларыңда тургай моңнары.
Батырларың бар дөньяга үрнәк
Туган җирем – Татарстаным
минем.



Туган якка юл тотамын
Туган як, туган як.
Иң гүзәл газиз якка
Туган як, туган як.
Җир җиләкләре пешкән
чак
Туган  як, туган як
Ашыгам каенлыкка
Туган як, туган як.
 - Талпына күңел,
 талпына ашкына
Ярсуына түз, түз генә
Каенлыкта җиләк пешкән,
Тиз үрелеп өз генә.

# Туган ягым табигате.



Кайда барсам, кайда булсам да мин,
Синең хакта минем уйларым.
Матурлыкка һич кул тидермәмен,
Мин саклармын сине, саклармын.

Тирәктәге сайрар кошларың да
Барысы да миңа кадерле,
Синең кебек манзаралы җирне
Беркайда да тапмам шикелле.



Җәй көннәрен болыннарда,
Чәчәкләрдән тәмле ис бөрки.
Каенлыкта зифа буйлы каен,
Әйтерсең лә миңа кул сирпи.

Чәчәкләрнең монда төрлесе бар
Агы, кызылы, һәтта зәңгәре.
Мондый җирдән ничек китеп бу
Китеп булмый инде, билгеле.


Җәннәт бакчасыдай туган җирем,
Һич кенә дә сине онытмам.

PPt4WEB.ru

“И туган тел» -иң әйбәт шигырь!
«Туган тел»-иң әйбәт җыр!
«Туган тел» -иң әйбәт китап!
«Туган тел» - иң әйбәт тел!
Туган тел әйбәт булганга,
Шигыре дә, китабы да,
Җыры да – иң әйбәттер.



**РОБЕРТ МИҢНУЛЛИН**




Туган тел – халыкларның
рухи байлыкларын
күрсәтүче генә түгел,
бәлки яхшы киңәшче дә.

**К.Д.УШИНСКИЙ**

MyShared


21 февраль -
Халыкара туган тел көне!
Туган телдә җырлый чишмә,
Туган телдә шаулый таллар.
Туган телдә дәшсәм генә,
Туган җирем мине аңлар.



# ЯРАТЫРГА КИЛДЕК БЕЗ БУ ЖИРГӘ!




ТАТАРСТАН
Синдә генә безнең язмышыбыз,

# Игътибарыгыз өчен рәхмәт!



***Төзеде ветеран укытучы, Россия Федерациясенең Мәгариф отличнигы Мәхтүмә  Минсафина.***

elenaranko.ucoz.ru